**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сәпәй авыл җирлеге Советы**

Сәпәй авылы № 113 “13” ноябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы “Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карары проекты турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Сәпәй авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 2012 елның 15 октябрендәге 46 номерлы Карары (2013 елның 24 июнендәге 61 номерлы, 2014 елның 27 мартындагы 85 номерлы, 2014 елның 15 августындагы 101, 2017 елның 25 августындагы 57 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын (1 нче кушымта) хупларга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 2012 елның 15 октябрендәге 46 номерлы Карары (2013 елның 24 июнендәге 61 номерлы, 2014 елның 27 мартындагы 85,2014 елның 15 августындагы 101, 2017 елның 25 августындагы 57 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында " гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

3. Билгеләргә:

- уздыру вакыты-2018 елның 26 ноябреннән 2018 елның 28 декабренә кадәр;

- үткәрү урыны- Сәпәй авылы авылы, Казан урамы, 19 йорт ;

– фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2018 елның 28 декабренә кадәр- Сәпәй авылы, Мәктәп урамы, 53В йорт, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге башкарма комитетына (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр төшке ашка 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр тәнәфес) кертелә ала.

4. Халык тыңлаулары үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркем төзү:

- Галиева Ф.Г. – Сәпәй авыл җирлеге башлыгы;

-Латыйпова Л.И. – Сәпәй авыл җирлеге Советының №5 округы депутаты;

-Гәрәйшин Н.Г. – Сәпәй авыл җирлеге Советының № 1 округы депутаты.

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 2012 елның 15 октябрендәге 46 номерлы Карары (2013 елның 24 июнендәге 61 номерлы, 2014 елның 27 мартындагы 85, 2014 елның 15 августындагы 101, 2017 елның 25 августындагы 57 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы “Сәпәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча эшче группага ачык тыңлаулар уздыруны, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссия, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә.

7. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән, 2018 елның 21 ноябреннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Ф.Г.Галиева

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл Советының
2018 елның 13 ноябрендәге 113 номерлы карарына

**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Сәпәй авыл җирлеге Советы**

Сәпәй авылы №___ __ _________ 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советы карары белән расланган 2012 елның 15.10. 46 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының " Сәпәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарга үзгзрешләр кертү турында (2013 елның 24.06. 61 номерлы, 2014 елның 27.03. 85 номерлы, 2014 елның 15.08. 101 номерлы, 2017 елның 25.08. 57 номерлы карарлар редакциясендә)

2017 елның 29 декабрендәге 463 номерлы Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының “Сәпәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Сәпәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә тулаем төзекләндерү объектларын чисталыкта һәм тәртиптә тотуга бердәм таләпләр билгеләү максатында,

Сәпәй авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Советының 15.10.2012 ел, № 46 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сәпәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә

(24.06.2013 ел №61, 27.03.2014 ел, № 85, 15.08.2014 ел, № 101, 2017 елның 25.08. 57 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 1.3 пунктта:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«территорияне төзекләндерү - гражданнарның яшәү шартларын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын яхшыртуга, торак пунктлар территорияләрен һәм мондый территорияләрдә урнашкан объектларны, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны карап тотуга юнәлтелгән әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән чаралар комплексын гамәлгә ашыру эшчәнлеге;»

б) түбәндәге эчтәлекле унҗиде абзац өстәргә:

«төзекләндерү элементлары-декоратив, техник, планлаштыру, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, җиһазларның һәм бизәлешнең төрле төрләре, шул исәптән биналарның фасадлары, төзелмәләр, корылмалар, кече архитектура формалары, стандарт булмаган корылмалар, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлеше буларак кулланыла торган күрсәткечләр.».

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 7.17 пункт өстәргә:

«7.17. Йорт тамгаларындагы , тышкы мәгълүмат чараларында мәгълүмат Россия Федерациясе дәүләт теле һәм Татарстан Республикасы дәүләт телләре турындагы закон таләпләрен үтәү белән урнаштырылырга тиеш. Ике һәм аннан да күбрәк тел куллану очрагында текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча охшаш , дөрес һәм аңлаешлы итеп эшләнгән булырга тиеш.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.